**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге Ялкын авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча**

17 декабрь 2021 е. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге Ялкын авылындагы гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа 1 төркем инвалидлар, студентлар, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнар керми, һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү:

- авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм төзекләндерү;
- каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү һәм карап тоту.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Ялкын авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

2. Әлеге карарны Ялкын авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районының
Ялкын авыл җирлеге башлыгы И.В.Гущина.